СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

*12 декабрь, 1997 ел.*
*ҖОМГА*

*Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга.*

*№ 140 (8152)*

*Бәясе билгеләнгәнчә*

## 12 декабрь - Россия Федерациясе Конституциясе көне

## Ял итәбез

Россия Федерациясе Президентының «Эш көне булмаган 12 декабрь турында»гы Указы нигезендә, Россия Федерациясе Конституциясе көне - 12 декабрь бәйрәм, ял көне булып тора.

Шәһәр һәм район хакимиятләре башлыкларына, хезмәт, матди һәм финанс ресурслары белән тәэмин ителгән предприятие һәм оешма җитәкчеләренә, кирәк булган очракта, 1997 елның 12 декабрендә Россия Федерациясенең Хезмәт турындагы законнар кодексының 65 һәм 89 нчы маддәләрендә билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда эшне оештырырга тәкъдим ителә.

**Татарстан Республикасының хезмәт һәм эш белән тәэмин итү дәүләт комитеты.**

## РЕСПУБЛИКА ХӘБӘРЛӘРЕ

### *Татарстанда ике автобус заводы бар*

***Республикабызда җитештерелә торган автомобильләр күпләргә билгеле: беренче чиратта, әлбәттә, «КамАЗ»лар, «Ока»лар, «Шевроле - Блейзер»лар... Бүген инде ике шәһәребез автобуслар җитештерү башкаласы исемен дәгъваларга җыена. Берсе - Чаллы, икенчесе - Зеленодол...***

### ЧАЛЛЫ

Узган атна ахырында башкалабызның 1 Май мәйданында әйләнешләр ясаган «ЧелАЗ - 5281» автобусы әлегә берданбер данәдә генә. Аны «Чаллы автобус заводы» ябык типтагы акционерлык җәмгыяте эшләп чыгарган.

«Чаллы автобус заводы» киләчәктә троллейбуслар җитештерә башларга да җыена. Әйе, анысы да Татарстанга бик кирәк.

### ЗЕЛЕНОДОЛ

Зеленодол пассажир автотранспорт предприятиесе цехында җыелган «КАРОСА» автобусына Татарстан Республикасы Президенты М.Шәймиев югары бәя бирде. Яшелүзәнлеләр киләсе елда шундый 50 автобус җыярга хөкүмәт заказы алдылар.

## Киңәшмәдә - Яңа елга әзерлек мәсьәләсе



Яңа ел якынлаша. Сишәмбе көнне район хакимиятенең кече залында шәһәр предприятиеләре һәм оешмалары җитәкчеләре, профсоюз комитетлары рәисләре катнашында үткән киңәшмәдә төп мәсьәлә аны ничек итеп каршылау һәм үткәрүгә багышланган иде. Хакимиятнең әйдәп баручы белгече Р.З.Сингатуллина үз чыгышында шәһәрне, аерым алганда аның микрорайоннарын, үзәк мәйданын бизәү буенча узган елгы һәм башка районнар тәҗрибәсеннән чыгып, быелгы оештыру комитеты аңа күп кенә өстәмәләр кертүен ассызыклап, залдагыларны яңа ел алды чаралары белән таныштырды, алар буенча җаваплы предпрятиеләр, оешмаларны атады. Алардан күренгәнчә, быел шәһәрнең барлык микрорайоннарында да чыршылар бизәләчәк. Үзәк мәйдандагы боздан шәһәрчек төзеләчәк. Шәһәрнең үзәк урамнарын бәйрәмчә яктыртуга да зур игътибар юнәлтелде киңәшмәдә. Боз таулары, таганнар, карусельләр ясау буенча да конкрет бурычлар куелды.

Киңәшмәдә шулай ук иң яхшы бизәлгән административ бина, балкон һәм тәрәзә, иң матур яктыртылган микрорайон чыршылар, боздан ясалган әкият персонажлары, Кыш бабай һәм Кар кызына, һ.б.га конкурс игълан ителүе җиткерелде.

Яңа ел бәйрәмен үткәрү көне 28 декабрьгә билгеләнде. Район мәдәният бүлеге дә бәйрәмгә зур хәзерлек алып бара. Мәдәният хезмәткәрләре декабрьнең 25еннән оешмалар һәм предприятиеләр заявкалары буенча коммерция нигезендә Чыршы бәйрәмнәре үткәрә башлаячаклар. Шулай ук бүлек каршында хезмәт күрсәтү бюросы да (Кыш бабай һәм Кар кызы котлавы) эшләячәк.

Киңәшмәдә чыгыш ясаган Норлат җирле үзидарә Советы рәисе Р.Г.Билалов та бәйрәмне тиешле дәрәҗәдә үткәрү өчен хәзерлекне бүгеннән башлап, декабрьнең 15нән җанлы гамәли эш җәелдерергә чакырды.

Киңәшмә эшенә район хакимияте башлыгының беренче урынбасары Ю.В.Терентьев җитәкчелек итте.

## Бер институтта биш «Ел кешесе»

Шушы көннәрдә Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институтына күңелле хәбәр килде. Америка Кушма Штатларындагы Биография институты, фән өлкәсендәге олы хезмәтләрен искә алып, күренекле галимнәр, филология фәннәре докторлары: Фатих Урманчеев, Хуҗиәхмәт Мәхмүтов, Нурмөхәммәт Хисамов, Мингали Арсланов, Назим Ханзафаровка 1997 елның «Ел кешесе» дигән исем биргән.

## Укучыларыбыз игътибарына!

**Газетабызның киләсе саны чәршәмбе, 17 декабрь көнне чыгачак.**



## Арбаны кыштан әзерлиләр

### Яз озак көттермәс

«Игенче» хуҗалыгының техника паркында зур җанлылык бүген. Механизаторлар эштән бушаган техниканы яхшылап кышкы саклауга урнаштыру белән мәшгуль булсалар, елның - елында ремонт белән шөгыльләнүчеләр инде кайбер төр авыл хуҗалыгы машиналарын һәм тагылма инвентарьны төзәтергә дә керешкәннәр. Соңгысы табигый хәл итеп каралырга тиеш булса да, әле күп хуҗалыкларда ремонт турында, кем әйтмешли, ике ятып бер төшләренә дә кермәгәндә монда шулай кызу эш баруына сокланмый мөмкин түгел. Әле башкалар үрнәк алсын, кайсыларына сабак та булсын өчен монда район семинары үткәрергә дә җыеналар. Әмма хуҗалыкның техника паркындагы җанлылык һич тә кунаклар килүе көтелгәннән түгел, ә һәр төр техниканы үз вакытында ремонтлап куеп, тегеяки бу кыр эшләренә тыныч күңел белән керешер өчен. Шунысы да игътибарга лаек, хуҗалыкта быел ремонтны фәкать үз көчләре белән башкарып чыгарга ниятләгәннәр. Хәер, хәзерге акча кытлыгы, бәяләрнең котырган чорында һәр хуҗалык та ремонтны үзендә генә башкарырга риза булыр иде анысы. Әмма моның өчен тиешле базасы, кирәкле материалы һәм, билгеле инде, оста куллы кешеләре дә кирәк бит әле. Беренчесенә килгәндә, хәзер хуҗалыкларның күбесендә заманында типовой проект буенча салынган техника мастерскойлары бар һәм аларда төрле хезмәтләр өчен махсус бүлмәләр дә каралган. Тик шул бүлмәләрне, алардагы җиһазларны максатчан файдалану гына һәркайда да юк. Ә менә «Игенче»дә ремонт мастерское чын - чынлап багъланышы буенча файдаланыла. Тимерчелек цехында хәзер тырмалар ремонтлау бара. Вазыйх Вәлиәхмәтов белән Таһир Миннеханов алты дистәдән артыграк тырманы төзәтеп куйганнар да инде. Икенче бер цехтагы эретеп ябыштыручыларга да эшнең бетеп торганы юк. Ул вазифада Рамил Зиннуров белән Рәхимҗан Сафин бирeдә. Нинди генә техниканы төзәтергә туры килми аларга. Мастерскойның өченче бер горурлыгы турында аерым әйтсәң дә артык булмастыр. Нурислам Закиров белән Гали Канәфин эшли торган бүлмәдә хуҗалыктагы һәр механизмга җан өреләә диярга мөмкин. Фермада транспортерның, ындыр табагында ашлык чистарту машинасының, я булмаса витаминлы үлән оны агрегатының электр моторы янып чыга икән, нәкъ менә шушы ике уңганга мөрәҗәгать итәләр. Күп хуҗалыклардагы шикелле әллә кайларга алып барып көтеп торасы да, миллионнарыңны чыгарып саласы да юк. Аеруча еш янып чыга торган электр моторларын запаска да әзерләп тоталар алар. Моторларның көнкүрештә кулланыла торганннарын да китерәләр аларга һәм егетләр аларын да менә дигән иттереп чорнап бирәләр. Алар күршесендәге цехта да кеше бетеп тормый. Моторлар буенча белгеч Рафаэль абый Әһлетдинов хуҗа анда. Бу арада аның да эше тыгыз чак - мастерскойга ремонтка кергән тракторлар аз түгел. Ә мастерскойның иң түрендәге цехта ике кыру станогы тора. Инде алтынчы дистәне тутырып килүче Әхәт абый Хәсәнов янына быелтыр Әмир Миннеханов та кушылган. Кайчандыр Чаллыга китеп барган егет хәзер туган авылына кайткан һәм һич тә үкенми - КамАЗдагы хәлнең ни чамалы икәнлеге билгеле бит. Ә монда ике куллап каршы алганнар егетне. Токарьлар икәү булса да, эш җитәрлек, әле менә чәчкечләрнең сошникларын кертеп тутырганнар яннарына. Кайралганнарын алып карадык - «Сельхозтехника»да сафка бастырылганнан бер дә ким түгел...

Кунакларны хуҗалыкның техник карау үткәрү пунктына да алып керми калмаячаклар. Биредә эшләүче Рәхимҗан ага Вәлиуллин турында моннан элек иркенләп язып чыккан идек. Чын хуҗаның хезмәт урынында да, эшендә дә элеккечә үк ныклы тәртип, кем әйтмешли, пунктына керсәң чыгып китәсең килмәслек. Үз вазифасын кем дә кушканны көтмичә, үзе белеп, үзенә генә хас пөхтәлек белән башкара Рәхимҗан ага. Әле менә запаска әзерләп куйган ягулык аппаратлары гына да дистәдән артып киткән. Ә инде форсункаларны ничек юктан бар иттерүе турында аерым иркенләп сөйләргә кирәк - телен чишеп, серен белешә алсаң, билгеле. Әнә шундый пөхтә белгеч янына техникаларына ярдәм алырга килүче механизаторларның да андагы ныклы тәртипкә буйсынмый хәлләре юк. Бу инде хуҗалыктагы техника паркына гомумән дә тәртип керә дигән сүз. Ә тәртип булган җирдә эш тә бүтән, нәтиҗәсе дә үзгә.

**Р.ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ.**

## Яңалык

### Комиссариат адресын үзгәртәчәк

Хәрби хезмәт комисариаттан башлана, диләр. Районыбызның 1934 нче елда төзелгән хәрби комиссариат бинасыннан шушы еллар эчендә күпме яшүсмер хәрби хезмәткә озатылган, күпме кеше шушы стеналар эчендә учетка баскан, хәрби документын рәсмиләштергән.

Якын елларда хәрби комиссариат адресын үзгәртергә җыена. Бу көннәрдә нәкъ менә Норлат - Чистай юлы башында район хәрби комиссариаты өчен яңа бинага нигез салынды. Төзелешне МСО алып бара. Ә бина үзе ике катлы булачак. Иркен эш кабинетлары, компьютер классы, медицина тикшерүе үткәрү өчен уңайлыклар - барысы да каралган анда. Янәшәгә үк гаражлар, ярдәмче биналар төзү дә күздә тотыла.

